**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

# КАРАР

«29» март 2018 ел Яр Чаллы шәһәре № 1079

Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучылар сыйфатында исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларны уллыкка (кызлыкка) алу һәм аларның тормыш шартларын һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданнары һәм чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар булып торучы балаларны исәпкә алу кагыйдәләрен раслау турында» 29.03.2000 № 275 санлы карарын (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә) тормышка ашыру максатларында һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексы нигезендә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитетның 2013 елның 13 ноябрендәге 5592 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучылар сыйфатында исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. п. 2.5. 1.1. Административ регламентны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

1.2. п. 3.4.1. гариза бирелгән көннән соң 2 эш көне эчендә опека һәм попечительлек органнарының гаризада күрсәтелгән белешмәләрне раслауны таләп итү бурычын билгели.

1.3. п. 3.5.1. опека һәм попечительлек органы Кагыйдәләрнең 4 пунктында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә) каралган мәгълүматларның тиешле вәкаләтле органнары тарафыннан расланганнан соң 3 эш көне эчендә баланы

уллыкка алырга теләүче затларның тормыш шартларын тикшерүне үткәрүне йөкли, аның барышында Россия Федерациясе Граждан кодексы тарафыннан баланы уллыкка алырга комачаулаучы шартлар булмау билгеләнә.

1.4. п. 3.5.3. гражданнарны уллыкка алу мөмкинлеге (булмавы) турында карар тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан Кагыйдәләрнең 4 пунктында каралган мәгълүматларны раслаган көннән сон 10 эш коне эчендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан кабул ителә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә).

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ф. Ганиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. М. Камаев